УДК 39

*Г.С. Хаҗиева*

# ТАТАР КУЛЬТУРАСЫНДА ГАЙШӘ-ФАТЫЙМА АГИОНИМЫ

В статье рассматривается бытующий в татарской народной культуре агионим Айше-Фатима. На основе изучения фольклорно-этнографических материалов, главным образом текстов заговорной традиции, выделено несколько локальных вариантов агионима. Путем этнолингвистического анализа проводится реконструкция народного образа соответствующего персонажа: выявляются его функциональные, атрибутивные, локативные и темпоральные характеристики. В текстах татарских локальных культур культ Айше-Фатима представлен как целитель от разных болезней, недугов и их имена используются в заговорах и заклинаниях при лечении болезней, в повивальных обрядах с новорожденными. Агионим Айше-Фатима выполняет и другие функции: служит одним из посредников между человеком и Аллахом, защищает людей от болезней и несчастий, обеспечивает их достатком и удачей. Вера в то, что агионим Айше-Фатимы является покровителем женщин восходит к древнетюркским традициям, которые перешли в исламскую культуру. В исследовании прослежены параллели агионима Айше-Фатимы в культурах некоторых других тюркоязычных народов.

**Ключевые слова**: татары, локальные культурные традиции, фольклор, заговоры, заклинания, агионимия, Айше-Фатима, этнолингвистика.

The article examines the agionym Aishe-Fatima that exists in the Tatar folk culture. Based on the study of folklore and ethnographic materials, mainly the texts of the conspiracy tradition, several local variants of the hagionym have been identified. By means of ethnolinguistic analysis, the folk image of the corresponding character is reconstructed: its functional, attributive, locative and temporal characteristics are revealed. In the texts of Tatar local cultures, the cult of Aishe-Fatima is presented as a healer from various diseases, ailments and their names are used in conspiracies and spells in the treatment of diseases, in obstetric ceremonies with newborns. Agionim Aishe-Fatima also performs other functions: it serves as one of the intermediaries between a person and Allah, protects people from diseases and misfortunes, provides them with prosperity and good luck. The belief that the agionym Fatima is the patron saint of women goes back to the ancient Turkic traditions that passed into the Islamic culture. The study traces the parallels of the agionym Aishe-Fatima in the cultures of some other Turkic-speaking peoples.

**Keywords:** Tatars, local cultural traditions, folklore, conspiracies, spells, agionymy, Aishe-Fatima, ethnolinguistics.

Ономастикада XX гасырның 90 нчы елларында агионимнар аерым категория булып аерылалар. Галим Н.В. Подольская «Рус ономастикасы терминология сүзлеге»ндә «агионимнар – изгеләрнең исемнәре» дип билгеләмә бирә [Подольская, 1978, с. 98]. И.В. Бугаева «агионим»ның изгелек белән бәйле затларның исемен белдерүен әйтә [Бугаева, 2007, с. 56]. Татар лексикологиясендә агионимнар мәсьәләсе

XX гасырның икенче яртысыннан ук (М.Х. Бакиров, Ф.И. Урманчеев, Х.Ш. Мәхмүтов, Г.Г. Гыйльманов, А.Х. Садекова, Ф.З. Яхин) өйрәнү объекты булып тора.

Татар культурасында им-том, теләк теләү текстларында төрле чирләрдән, күз тиюдән дәвалауда Гайшә-Фатыйма исеме киң кулланыла. Халык им-томнарында әлеге образ ислам мәдәниятендә киң таралган Гайшә һәм Фатыйма исемнәренә барып тоташа. Ислам тарихында танылган Гайшә – Мөхәммәд пәйгамбәрнең хатыны, ислам теологиясендә «дин тотучыларның анасы» дигән мактаулы титул белән дан тоткан. Фатыйма – Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы, Али Әбу Талибның хатыны, Хәсән һәм Хөсәеннең әнисе, мөселман дөньясында иң хөрмәтле хатын-кызларның берсе. Татар телендә Гайшә исеме гарәп телендә «тере» дигән мәгънәдә килә [Саттаров, 2020, б. 56], Фатыйма исеме гарәп телендә «күкрәктән аерылган кыз, яшүсмер» дигәнне белдерә [Саттаров, 2020, б. 98]. Билгеле булганча, әйләнә-тирә дөньяга йогынты ясау, теләгән күренешне чакыру, дини образларга мөрәҗәгать итеп, төрле хәрәкәтләр башкару им-том текстларының төп максаты булып тора. Татар диалектларында Әйшә-Гайшә исеменнән ясалган «әйшәләү» фигыле «нинди дә булса им-том ясау» дигәнне белдерә [Әхмәтьянов, 2005, б. 35].

Гайшә-Фатыйма образының хатын-кызларның яклаучысы булган борынгы төрки традициядә билгеле Умай образы белән тиңдәшлеген ассызыкларга мөмкин. Төрки мәдәниятләрдә ислам кабул ителгәч, дин белән бергә Гайшә-Фатыйма образы да халык арасында киң тарала башлый. Төрки мәдәниятләрдә Гайшә-Фатыйма образында Умай вазифаларына якынлык сизелә. Билгеле булганча, Умай борынгы төркиләрнең хатын-кызларны һәм балаларны саклаучы хатын-кыз алиһәсе буларак билгеләнә [Мифы народов мира, 2008, с. 91]. Умай – борынгы төрки мифологиядә җирнең уңдырышлылыгын гәүдәләндерүче образ. Ул яңа туган баланы бу дөньяга кабул итә, балаларны һәм сугышчыларны яклый, тормыш көчен гәүдәләндерә. Ислам дине кабул ителгәч, Умай исеме әкренләп онытыла башлый. Халык традицияләрендә изге мөселман хатын-кызларының вазифаларын чагылдырган Гайшә-Фатыйма исеме халык арасында киң таралыш таба:

*Им булсын, минем кулым түгел, Әйшә-Фатыйма куллары, дип такмаклап-такмаклап чабам баланы мунсада. Тәүфикъле бала картәнәсен дә картатасын да тыңлаучан була. Минем кулым түгел, Әйшә-Фатыйма кулы*[1].

(Татарстан Республикасы, Теләче районы,
Югары Мәтәскә авылы, информант Г. Нигъмәтҗанова)

---

[1] Әлеге мисаллар ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел. әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан үткәрелгән фәнни экспедицияләр материалларыннан алынды.

Им-том текстларында «Әйшә-Фатыйма кулы», «Аша-Батман кулы» гыйбарәләре киң таралган.

*Минем кулым түгел*
*Әйшә Батыйма кулы*
*Йакшыларның кулы*
*Минем кулым түгел,*
*Фатыйма белән Гайшәнең кул айагы,*
*Йабышкан кулымның сихәте килеп,*
*Изгеләрнең, әүлийәләрнең хәер-догаларында.*
*Өшкергән тынымның шифасы тисен,*
*Бу бала сихәтләнсен.*

(Свердловск өлкәсе, Красноуфим районы,
Шаралы авылы, информант З. Хәбирова)

Халык медицинасында Гайшә-Фатыйма исеме еш телгә алына. Себелеп яшәгән татарларның җирле сөйләшләрендә авыруларга каршы им-том ясаганда, әлеге исемгә мөрәҗәгать итәләр. Күз авыруларын дәвалау барышында, Гайшә-Фатыйма исеме магик көчләргә йогынты ясау чарасы буларак хезмәт итә. Казан арты татарлары, күзгә арпа чыккач, арпа бөртекләрен алып, Гайшә-Фатыйма исемен им-том сүзләрендә кулланалар. Им-том сүзләре әйтелгәч, арпа орлыгын этләргә ташлыйлар. Халык медицинасында күз тиюдән имләүдә, халык түбәндәге им-том сүзләрен файдалана:

*Ак күз, кара күз*
*Белгән күз, белмәгән күз*
*Зәңгәр күз, коныр күз, усал күз*
*Чыксын да китсен,*
*Бала өстендә тормасын*
*Мин эшкермим*
*Аша Батман карчыгы килгән*
*Шул өшкерә, шул чыга.*

(Татарстан Республикасы, Теләче районы,
Югары Мәтәскә авылы, информант Г. Нигъмәтҗанова)

Халык арасында очан авыруын дәвалаганда, Гайшә-Фатыйма исеме белән им-том йоласы үткәрелә.

*Нәрсә булган? – Очан булган,*
*Нәрсә имнисен? – Очан имним,*
*Җиде – җилгә кузгалсын,*
*Биш – бизеп китсен,*
*Өч – очып китсен,*
*Бер – берлексез булсын.*
*Минем кулым түгел,*
*Гайшә-Батман кулы, бетсен-китсен, –*
дип имнисен, тфү-тфү, дип.

(Әстерхан өлкәсе, Красноярск районы,
Сәет авылы, информант Д. Бәйрәмгазиева)

Тәндәге кызыл тимгелләрне дәвалагандагы им-том текстларында Гайшә-Фатыйма исеме очрый. Самара өлкәсе татарлары биттәге бетчәләрне дәвалау вакытында, кызыл сөлге белән каплап, түбәндәге им-том сүзләрен әйтәләр:

*Нәстә имлисен? Менә канчау канчаулыйм, Кайан килдең – шунда кит, Бүре эзенә бассаң – бүрегә кит, Кочок эзенә бассаң – кочокка кит, Сихергә эләксәң – сихерчегә кит, Бозыкка эләксәң – бозучыга кит, Кем бозган – шуңа китсен. Минем кулым түгел, Әйшә-Фатыйма кулы.*

(Татарстан Республикасы, Актаныш районы,
Качкын авылы, информант Ф. Сәмитова)

Гайшә-Фатыйма исеменә бала тугач та мөрәҗәгать итәләр. Әйтик, яңа туган сабыйны беренче тапкыр мунчада себерке белән чапканда, кендек әбисе Гайшә-Фатыйма исемен телгә алып, балага бәхет-тәүфыйк сорый:

*Аю баласын чабам,*
*Бүре баласын чабам.*
*Аю кебек симез бул,*
*Бүре кебек җитез бул.*
*Көндез уйна, кич йокла,*
*Бәхетле бул, тәүфыйклы бул.*
*Әйшә-Батман куллары, –*
*Име-йомы шул булсын, –*
*дип, бәхет сорап чапканнар баланы.*

(Свердловск өлкәсе, Красноуфим районы,
Шаралы авылы, информант З. Хәбирова)

Татар культурасында өй хуҗалыгында ярдәм сораганда да, Гайшә-Фатыйма образына мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, Себер татарлары җиләк-җимеш һәм гөмбә җыйганда, Гайшә-Фатыймадан ярдәм сорыйлар:

*Киттек сунарге, Алла хәерле юллар булсын, Безгә яраткан Алла Гайшә пәйгәмбәргебез Фатыйма бәйрәм-бәргебез яраткан Алла безгә бик күп тынычлык бирсен, Юлыбыз булсын. Гафу итсен!*

(Свердловск өлкәсе, Красноуфим районы,
Шаралы авылы, информант З. Хәбирова)

Татар культурасында Гайшә-Фатыйма исемен балаларның төрле авыруларын дәвалау процессында файдаланалар:

*Берәү-икәү... Тугыз – туфракка,*
*Җиде – җилкенеп җөргән кызларга,*
*Биш – бишесе биш калага,*
*Бишесе – биш салага,*
*Өс – өссөн, бетсен, китсен җилгә, кузга дисен,*
*Бер – бетеп китсен.*

(Татарстан Республикасы, Актаныш районы,
Качкын авылы, информант Ф. Сәмитова)

Әйшә-Фатыйма исеме балаларның курку чиреннән дә коткара:

*Әй, йөрәк, кайт, йөрәк,*
*Ай кайтты, син дә кайт,*
*Көн кайтты, син дә кайт!*
*Куй башыдай көмеш йөрәк,*
*Имләмәсәм – миңа язык,*
*Им булмаса – сиңа язык.*
*Минем кулым түгел,*
*Гайшә-Фатыйма апалар кулы.*

(Свердловск өлкәсе, Красноуфим районы,
Шаралы авылы, информант З. Хәбирова)

Төрки культурада Гайшә-Фатыйма культы бик киң таралган. Сабыйга бәхет, сәламәтлек, озын гомер теләп, аны начар көчләрдән саклау максатыннан, изге хатын-кыз Гайшә-Фатыйманың исеме искә алына.Үзбәк культурасында да, балага бәхет теләгәндә, Гайшә-Фатыйма исеме атала:

*Менинг қўлим эмас, биби фотиманинг Қўли, Әнвәр Онамнинг қўли, етти момонинг қўли» «бу минем кулым түгел, ул биби Фатыйма, Әнбәр ул, җиде Момо» дигән сүзләр белән мөрәҗәгать иттәләр.*

(Әстерхан өлкәсе, Красноярск районы,
Сәет авылы, информант Д. Бәйрәмгазиева)

Башкорт мифологиясендә Ғәйшә-Батима, Әйшә-Батман образы авыру балаларның, хатын-кызларның яклаучысы булып санала. Ғәйшә-Фатыйма ҡулы, Ғәйшә-Фатыйма теле, Гайшә-Фатыйма сөйләме кебек гыйбарәләр башкорт магик йолаларында, им-томнарында, теләкләрдә очрый. Мәсәлән, сабыйга бәхет, сәламәтлек, озын гомер теләү, шулай ук аны начар көчләрдән саклау максатыннан, мунча кертү йоласында изге хатын-кыз Гайшә-Фатыйманың исемнәре искә алына [Хисамитдинова, 2010]. Чуваш культурасында явыз рухны куу, авыруны дәвалау һәм аның сәламәтлеген ныгыту өчен, магик ритуаллар вакытында сихерчеләр Ашапатман картына мөрәҗәгать итәләр, аның исеменнән магик гамәлләр кылалар [Матвеев, 2004, с. 97]

Азәрбайҗан культурасында *Фатыйма куллары* термины киң таралган. Бала туу, кендек кисү йолаларында Гайшә образы түгел, Фатыйма кулы искә алына: *Минем кулым, Фатыйма кулым* [Qarayeva, 2017, s. 201].

Шулай итеп, әлеге мисаллардан күренгәнчә, татар һәм башка төрки халыкларның традицияләрендә Гайшә-Фатыйма исеменең берничә вазифасын билгели алабыз. Беренчедән, Гайшә-Фатыйма – барлык хатын-кызларның яклаучысы, икенчедән, изгеләр вазифасын башкарып, кеше белән Аллаһы Тәгалә арасында арадашчы функцияләрен үти. Өченчедән, бу исем берәр авырудан, бозымнан, күз тиюдән коткара һәм төрле чирләрне дәвалауда катнаша, дүртенчедән, Гайшә-Фатыйма кешеләрнең нәсел-нәсәбен яман чирләрдән һәм бәхетсезлекләрдән

саклау һәм яклау вазифасын башкара, исемен телгә алган сораучыларга бәхет һәм уңыш китерә. Моннан тыш, татарлар бу агионимга яхшы уңыш алу, өйдә иминлек саклау, сәламәтлек сорау өчен дә мөрәҗәгать итәләр. Гомумтөрки контекстында Гайшә-Фатыйма аерым урын алып тора. Татар халкының күзаллавында Гайшә-Фатыйма исеме Коръән белән тыгыз бәйләнгән. Әлеге персонаж төрле этномәдәни традицияләргә караган төрле катламнарның синтезыннан гыйбарәт. Татарларның җирле сөйләшләрендә сакланган им-том текстларында Гайшә-Фатыйма гадәттән тыш хәлләрдә ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм кулы сузучыны чагылдыра. Һәр төрки мәдәният бу образда үз колоритын гәүдәләндерә һәм мәдәният текстларында аның үз этнокультура киңлеге сурәтләнә. Им-том текстларында Гайшә-Фатыйма трансформациягә дучар ителгән, ул халык аңында бары тик яклаучы буларак кабул ителә.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015.

*Бакиров М. Х.* Татарский фольклор. Казань: Изд-во АН РТ, 2018.

*Бугаева И.В.* Агионимы в православной среде: структурно-семантический анализ М.: ФГОУ ВПО РГАУ – МСХА им. К.А. Тимирязева, 2007.

*Гыйльманов Г. Г.* Татар мифлары: иялэр, ышанулар, ырымнар, фаллар, имтомнар, сынамышлар,йолалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.

*Мәхмүтов Х. Ш.* Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVII йөз төрки-татар ядкярләрендә афоризмнар). Казан : Фикер, 2002.

*Мифы народов мира*: энциклопедия: в 2 т. / гл. ред. С.А. Токарев. М.: Советская энциклопедия, 2008.

*Подольская Н.В.* Словарь русской ономастической терминологии. М.: Наука, 1978.

*Садекова А. Х.* Религиозный фольклор в татарской литературе XII – начала XX в. Казань: ИЯЛИ, 2014.

*Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020.

*Урманчеев Ф. И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 т. Т. 1: А–Г. Казан: Мәгариф, 2009.

*Хисамитдинова Ф.Г.* Мифологический словарь башкирского языка. М.: Наука, 2010.

*Яхин Ф.З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.

*Матвеев Г.М.* Мифоязыческая картина мира чувашского народа. Чебоксары: Изд-во Чуваш. ун-та, 2004.

*Qarayeva A.V.* Azerbaycan Dilinde Dini ve Mifoloji leksika. Filologiya üzrə fəlsəfə doktoru elmi dərəcəsi almaq üçün təqdim edilmiş dissertasiyanın aftoreferatı. Baku, 2017.

***Хаҗиева Гүзәлия Сәйфулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт мәдәният институтының универсаль компетенцияләр методологиясе һәм технологиясе кафедрасы мөдире*